ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.12.2024 Балык Бистәсе штп. №355пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган төгәлләнмәгән төзелеш объектларын һәм (яисә) төгәлләнмәгән төзелеш объектларында башкарылган чыгымнарны исәптән чыгару турында карарлар кабул итү Кагыйдәләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Финанс белән тәэмин ителеше Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектларын яисә төгәлләнмәгән төзүгә тотылган чыгымнарны исәптән чыгару турында карарлар кабул итү Кагыйдәләрен раслау хакында» 05.07.2022 № 638 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган төгәлләнмәгән төзелеш объектларын һәм (яисә) төгәлләнмәгән төзүгә тотылган чыгымнарны исәптән чыгаруны килештерү буенча комиссия төзергә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган төгәлләнмәгән төзелеш объектларын һәм (яисә) башкарылган чыгымнарны исәптән чыгару турында карарлар кабул итүнең кушымта итеп бирелә торган Кагыйдәләрен расларга.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган тәмамланмаган төзелеш объектларын һәм (яисә) тәмамланмаган төзелеш объектларына чыгымнарны муниципаль заказчылар тарафыннан исәптән чыгару тәртибе турындагы

нигезләмәне раслау хакында»24.12.2021 №284пи карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Д. А. Сатдинов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 28.12.2024 № 355пи карары белән расланган

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган тәгәлләнмәгән төзелеш объектларын һәм (яисә) тәгәлләнмәгән төзелеш объектларында башкарылган чыгымнарны исәптән чыгару турында карарлар кабул итү Кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган тәгәлләнмәгән төзелеш объектларын һәм (яисә) тәгәлләнмәгән төзүгә тотылган чыгымнарны исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибен билгели.

2. Исәптән чыгару турында карар кабул ителә:

а) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының милек хокуклары Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән тәгәлләнмәгән төзелеш объектлары(алга таба - тәгәлләнмәгән төзелеш объектлары);

б) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган, проект һәм (яисә) эзләнү эшләренә чыгымнарны (алга таба-башкарылган чыгымнарны) кертеп, тәгәлләнмәгән төзүгә тотылган чыгымнар.

3. Тәгәлләнмәгән төзелеш объектларын исәптән чыгару турында карар түбәндәге нигезләр булганда кабул ителә:

а) тәгәлләнмәгән төзелеш объектын хосусыйлаштыру өчен Россия Федерациясенең хосусыйлаштыру турындагы законнарында каралган нигезләрнең булмавы;

б) чикләрендә төзелеп бетмәгән объект урнашкан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органы тәгәлләнмәгән объектны түләүсез кабул итүдән баш тартканда.

4. Башкарылган чыгымнарны исәптән чыгару турында карар түбәндәге нигезләр булганда кабул ителә:

а) капитал салулар проект һәм (яисә) эзләнү эшләренә башкарылган, аларның нәтиҗәләре буенча проект документациясе биш ел элек расланмаган яисә расланмаган, ләкин Типовой документация реестрына кертелмәгән яисә кабат файдалануның икътисадый нәтиҗәле проект документациясе дип танылмаган;

б) "Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында" 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясында каралган Бердәм

дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында чыгымнар башкарылган тәгәлләнмәгән төзелеш объектларына хокукларны дәүләт теркәвенә алу өчен нигезләрнең булмавы.

5. Исәптән чыгару турында карар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары рәвешендә кабул ителә.

6. Тәгәлләнмәгән төзелеш объектын исәптән чыгару турындагы карарда түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә башкарма органы исеме;

б) тәгәлләнмәгән төзелеш объектының исеме, шулай ук аның урнашу урыны, кадастр номеры һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милегенең реестр номеры;

в) тәгәлләнмәгән төзелеш объектын сүтү һәм (яисә) төзелеш калдыкларын утильләштерү һәм тәгәлләнмәгән төзелеш объектын рекультивацияләү зарурлыгы турында, әлеге чараларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле акчаларның күләме срокларын һәм исәп-хисабын үз эченә алган җир кишәрлеген рекультивацияләү турында һәм (яисә) капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыру турында карарга үзгәрешләр кертү хакында карар, аның нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанс белән тәэмин итү башкарылган (мондый карар булган очракта).

7. Башкарылган чыгымнарны исәптән чыгару турындагы карарда түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә башкарма органы исеме;

б) бухгалтерлык исәбендә башкарылган капитал салулар исәпкә алынган юридик зат исеме;

в) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән башкарылган чыгымнар күләмен күрсәтеп, башкарылган чыгымнарның гомуми күләме һәм аларны төрләр буенча бүлү (проект һәм (яисә) эзләнү эшләре, төзелеш-монтаж эшләре, капиталь төзелеш объектын төзү сметасына кертелгән җиһазлар сатып алу) (мондый мәгълүмат булганда);

г) чыгымнар башкарылган чор.

8. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан тәмамланмаган төзелеш объектларын һәм (яисә) башкарылган чыгымнарны исәптән чыгаруның максатка ярашлылыгын карау өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын финанслар белән тәэмин итү Балык Бистәсе бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган тәгәлләнмәгән төзелеш объектларын һәм (яисә) тәгәлләнмәгән төзүгә тотылган чыгымнарны исәптән чыгаруны килештерү буенча комиссия төзелә. (алга таба - комиссия).

9. Объектларны исәптән чыгаруны һәм (яисә) башкарылган чыгымнарны килештерү турында комиссия карар кабул итү өчен нигез булып түбәндәге шартларның берсе булу тора:

а) тәгәлләнмәгән төзелеш объектын хосусыйлаштыру өчен Россия

Федерациясенең хосусыйлаштыру турындагы законнарында каралган нигезләрнең булмавы;

б) чикләрендә төзелеп бетмәгән объект урнашкан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органы төгәлләнмәгән объектны түләүсез кабул итүдән баш тарту.

10. Башкарылган чыгымнарны исәптән чыгаруны килештерү турында комиссия карар кабул итү өчен түбәндәге шартларның булуы нигез була:

а) капитал салулар проект һәм (яисә) эзләнү эшләренә башкарылган, аларның нәтиҗәләре буенча проект документациясе биш ел элек расланган яисә расланмаган, ләкин типовой документация Реестрына кертелмәгән яисә кабат файдалануның икътисадый нәтиҗәле проект документациясе дип танылмаган;

б) "Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында"2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясында каралган Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында чыгымнар башкарылган төгәлләнмәгән төзелеш объектларына хокукларны дәүләт теркәвенә алу өчен нигезләрнең булмавы.

11. Муниципаль заказчы, әлеге Кагыйдәләрнең 13 һәм 14 пунктларында күрсәтелгән документларны кушып, һәр объект һәм (яисә) башкарылган чыгымнар буенча үтенечнамәне комиссия рәисе адресына җибәрә.

12. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә (транспорт инфраструктурасы өлкәсендә төгәлләнмәгән төзелеш объектлары буенча), Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына алына һәм кабул ителә торган карарның финанс-икътисадый нигезләвенә таянып, алга таба чыгымнарны башкару мөмкинлеген һәм (яисә) максатка ярашсызлыгын нигезләүче аңлатмалы материаллар белән исемлек проекты әзерләнә һәм килештерүгә җибәрелә. Исәптән чыгару турындагы карар проектын килештерү срогы ул кергән көннән алып 14 календарь көннән артмаска тиеш, күрсәтелгән срокта җаваплар булмаган очракта, исәптән чыгару турындагы карар проекты килештерелгән дип санала.

13. Төгәлләнмәгән төзелеш объектын исәптән чыгару турында Карар кабул итү өчен әлеге Кагыйдәләрнең 11 пунктында күрсәтелгән үтенечнамә белән берлектә муниципаль заказчы комиссиягә түбәндәге документларны һәм мәгълүматны тапшыра:

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органы йә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы исеменнән эш итүче муниципаль казна учреждениесе исеме;

- төзелеп бетмәгән объектның исеме, шулай ук аның урнашу урыны, кадастр номеры һәм муниципаль милекнең реестр номеры; - төгәлләнмәгән төзелеш объектын сүтү һәм (яисә) төзелеш калдыкларын утильләштерү һәм төгәлләнмәгән төзелеш объектын рекультивацияләү зарурлыгы турында, әлеге чараларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләме срокларын һәм хисапларын үз эченә алган җир кишәрлеген рекультивацияләү турында һәм (яисә) капиталь кертемнәрне гамәлгә ашыру турында карарга үзгәрешләр кертү турында карар, аның нигезендә Татарстан

Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанс белән тәэмин итү башкарылган (мондый карар булган очракта); - төгәлләнмәгән төзелеш объекты исеме;

- төгәлләнмәгән төзелеш объектының инвентарь (исәп) номеры (булган очракта);

- төзелеп бетмәгән объектның кадастр номеры;

- төзелеп бетмәгән объект төзелә башлаган ел;

- тәмамланмаган төзелеш объектының күчемсез төзелеш объектын исәптән чыгару турында карар кабул ителгән көнгә баланс бәясе;

- төгәлләнмәгән төзелеш объектының кадастр бәясе;

- төгәлләнмәгән төзелеш объектына карата күчемсез мөлкәт объекты турында Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрыннан өземтә;

- төзелеп бетмәгән объектка карата күчемсез мөлкәт объекты турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милек реестрыннан өземтә;

- төзелеп бетмәгән объект урнашкан җир кишәрлеге турында мәгълүмат;

14. Әлеге Кагыйдәләрнең 11 пунктында күрсәтелгән үтенечнамә белән бергә башкарылган чыгымнарны исәптән чыгару турында карар кабул итү өчен муниципаль заказчы комиссиягә түбәндәге документларны һәм мәгълүматны тапшыра:

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органы йә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы исеменнән эш итүче муниципаль казна учреждениесе исеме;

- бухгалтерлык исәбендә башкарылган капитал салулар исәпкә алынган юридик зат исеме;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән башкарылган чыгымнар күләмен күрсәтеп, башкарылган чыгымнарның гомуми күләме һәм аларны төрләр буенча бүлү (проект һәм (яисә) эзләнү эшләре, төзелеш-монтаж эшләре, капиталь төзелеш объектын төзү сметасына кертелгән җиһазлар сатып алу) (мондый мәгълүмат булганда);

- чыгымнар башкарылган чор;

- төзүгә чыгымнар ясалган объектның исеме;

-мондый документлар булганда капиталь төзелештә эшләрне исәпкә алу буенча беренчел исәпкә алу документлары (башкарылган эшләрне кабул итү турында актлар (КС-2), башкарылган эшләрнең һәм чыгымнарның бәясе турында белешмәләр (КС-3), кабул итү комиссиясенең төзелеш тәмамланган объектын кабул итү актлары (КС-14), ТОРГ-12 номерлы форма буенча товар накладнойлары, башка документлар));

- тотылган чыгымнарның күләме;

- тотылган чыгымнарны гамәлгә ашыра башлаган ел.

15. Комиссия әлеге Кагыйдәләрнең 21 пунктында билгеләнгән срокларда объектны исәптән чыгаруны һәм (яисә) башкарылган чыгымнарны килештерү турында йә сәбәпләрен күрсәтеп, аннан баш тарту турында Карар кабул итә. Карар комиссия утырышы беркетмәсендә чагыла.

Әлеге Кагыйдәләрнең 13, 14 пунктларында санап үтелгән тапшырылган документлар нигезендә муниципаль заказчылар балансындагы объектны һәм (яисә) башкарылган чыгымнарны исәптән чыгару турында Карар кабул итү мөмкин булмаса, комиссия өстәмә рәвештә төгәлләнмәгән төзелеш объектларының техник торышына йә махсуслаштырылган оешма тарафыннан башкарылган проект документациясенә бәйсез экспертиза, шулай ук фактта башкарылган эшләр күләменә һәм аларның туры килүенә экспертиза ясауны, башкарылган эшләрне КС-2 формасы буенча кабул итү турында актларсоратып алырга хокуклы;

Комиссия тарафыннан карар кабул итү срогы бәйсез экспертиза уздыру вакытына озайтыла.

16. Төгәлләнмәгән төзелеш объектын һәм (яисә) төгәлләнмәгән төзелеш объектларына башкарылган чыгымнарны исәптән чыгаруны килештерүдән баш тарту өчен нигезләр булып тора:

- әлеге Кагыйдәләрнең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләрнең булмавы;

- әлеге Кагыйдәләрнең 13, 14 пунктларында каралган белешмәләрнең һәм документларның булмавы;

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының әлеге Кагыйдәләрнең 12 пунктында күрсәтелгән төзелеп бетмәгән объектлардан киләчәктә файдалану яисә башкарылган чыгымнар нәтиҗәләре турында тәкъдимнәре булу.

17. Комиссия тарафыннан әлеге Кагыйдәләрнең 16 пунктындагы 2 пунктчасында каралган нигез буенча исәптән чыгару турындагы карар проектын килештерүдән баш тарту турында Карар кабул ителгәндә, муниципаль заказчы мондый нигезне бетерә һәм әлеге Кагыйдәләрдә каралган тәртиптә исәптән чыгару турындагы карар проектын килештерүгә кабат җибәрә.

18. Әлеге Кагыйдәләрнең 13, 14 пунктлары нигезендә тапшырылган документлар комиссия утырышларында карала. Комиссия утырышларны документлар кергән саен комиссия рәисе карары буенча үткәрә. Комиссия утырышы кворум булганда хокуклы, ул комиссия составы әгъзаларының кимендә өчтән икесен тәшкил итә.

19. Комиссия түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

- әлеге Кагыйдәләрнең 13, 14 пунктларында каралган документларны карый;

- объектны төзеп бетерүнең максатка ярашлылыгы, аерым узел, детальләрдән, конструкцияләрдән һәм материаллардан файдалану мөмкинлеге, проект документациясен алга таба куллануның максатка ярашлылыгы мәсьәләләре буенча карарлар кабул итә;

- объектны һәм (яисә) башкарылган чыгымнарны исәптән чыгару сәбәпләрен билгели;

- объектны һәм (яисә) башкарылган чыгымнарны исәптән чыгаруны килештерү турында йә комиссия утырышы беркетмәсенә имза салу юлы белән исәптән чыгаруны килештерүдән баш тарту турында карар кабул итә.

20. Комиссия карарлары комиссиядә катнашучы әгъзаларның гомуми санынннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәдә утырышның датасы, анда катнашучы затларның фамилияләре, көн

тәртибе, кабул ителгән карарлар һәм ачык тавыш бирү нәтиҗәләре күрсәтелә. Тавышлар тигез булганда комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

21. Комиссия тарафыннан тапшырылган документларны карау һәм беркетмәне муниципаль заказчыга карар белән җибәрү срогы алар кергән көннән 30 календарь көннән артмаска тиеш.

22. Объектны һәм (яисә) башкарылган чыгымнарны исәптән чыгаруны килештерү турында уңай бәяләмә алган очракта, муниципаль заказчы бер ай эчендә төгәлләнмәгән төзелеш объектларын һәм (яисә) башкарылган чыгымнарны исәптән чыгару турында әлеге карарлар кабул итү кагыйдәләре нигезендә объектны һәм (яисә) башкарылган чыгымнарны исәптән чыгару турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәсе проектын әзерли, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының тәмамланмаган төзелешенә тотылган капиталь төзелеш объектларын финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла һәм аны билгеләнгән тәртиптә килештерүне тәэмин итә.

23. Объектларны һәм (яисә) башкарылган чыгымнарны исәптән чыгару турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты кабул иткән күрсәтмә нигезендә муниципаль заказчы объектны һәм (яисә) башкарылган чыгымнарны кушымтадагы форма буенча исәптән чыгару актын әлеге Кагыйдәләргә рәсмиләштерә һәм бухгалтерлык (бюджет) исәбе турында норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә исәптән чыгаруны тәэмин итә.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган тәгәлләнмәгән төзелеш объектларын һәм (яисә) тәгәлләнмәгән төзелеш объектларында башкарылган чыгымнарны исәптән чыгару турында карарлар кабул итү Кагыйдәләренә кушымта

Форма

## Тәмамланмаган төзелеш объектын һәм (яки) чыгымнарын исәптән чыгару акты

N _______________ "__" _________ 20__ ел

Муниципаль заказчы исеме
______________________________________________________________________________

Тәмамланмаган төзелеш объекты исеме
______________________________________________________________________________

Нигезләү
______________________________________________________________________________

Объектны һәм(яки) чыгымнарны исәптән чыгару сәбәбе
______________________________________________________________________________

| N п/п | Тәмамланмаган төзелеш объекты турында мәгълүмат | |
|---|---|---|
| 1. | Объект урнашкан урын | |
| 2. | Муниципаль заказчы турында мәгълүмат | |
| 2.1. | Җитәкче Ф.И.О.сы, вазифасы (телефон/факс) | |
| 2.2. | ИНН | |
| 2.3. | Код ОКПО | |
| 2.4. | Код ОКДП (эшчәнлек төре) | |
| 2.5. | Код СООГУ (югарыдагы орган) | |
| 3. | Объектның билгеләнеше | |

| | | |
|---|---|---|
| 4. | Җир-хокук документларының булуы | |
| 5. | Проект-смета документларының булуы | |
| 6. | Төзелеш сроклары | |
| 6.1. | Төзелеш башлау датасы | |
| 6.2. | Төзелешне фактта төгәлләү датасы | |
| 7. | Объектны финанслау суммасы | |
| 8. | Башка чыгымнар | |
| 9. | Төзелешнең башкарылу дәрәҗәсе | |

Муниципаль заказчы җитәкчесе:

______________ ____________________________

(имза) (имза расшифровкасы)

Баш бухгалтер:

______________ ____________________________

(имза) (имза расшифровкасы)

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 28.12.2024 № 355пи карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган төгәлләнмәгән төзелеш объектларын һәм (яисә) төгәлләнмәгән төзүгә тотылган чыгымнарны исәптән чыгаруны килештерү буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Сатдинов Данис Габделхарис улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Ризаев Дамир Наил улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Хәкимуллин Айрат Альберт улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Хәмидуллин Ирек Мәсгут улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы, комиссия секретаре |

Комиссии әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Петрова Эльвина Замир кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Потапова Диләрә Рафис кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының |

| | |
|---|---|
| | территориаль үсеш бүлеге башлыгы |
| Ногманова Ильсия Мәлик кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Кәлиев Булат Рөстәм улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппаратының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| | Территориясендә төзелеп бетмәгән төзелеш объекты булган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы вәкиле (килешү буенча) |